КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 август г.Казань № 743

Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 26 август, 743 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба - муниципаль берәмлек) бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар (алга таба - башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлеккә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән раслан «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасына кушымтаның 2.4 пунктында каралган юл билгеләре белән Казан шәһәре урам-юл челтәре участокларын җиһазландыру чараларын гамәлгә ашыру кысаларында бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертларны баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып тора:

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чаралар исемлеген раслаучы муниципаль хокукый акт булу ;

муниципаль берәмлек бюджетында финанслау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең тулы күләмдә финанслашуга бүтән бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба - килешү) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен муниципаль берәмлек Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләренә туры китереп, муниципаль берәмлекнең урам-юл челтәрендә урнаштырырга (алмаштырырга) планлаштырылган юл билгеләренең гомуми саны турында ирекле рәвештә башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза;

агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты турында (җыелма бюджет язмасы) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү планлаштырыла торган чаралар исемлеген гамәлгә ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен муниципаль берәмлек
бюджетында бюджет ассигнованиеләре булуын раслый торган һәм вәкаләтле зат тарафыннан расланган өземтә .

7. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көннән бер эш көне эчендә теркәлә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турындагы карар Министрлык тарафыннан гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә кабул ителә.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын муниципаль берәмлек тарафыннан үтәмәү;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

аларда булган документларның әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве.

10. Гариза кире кагылган сәбәпләрне күрсәтеп, бүтән бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында белдерү, гариза теркәлгән көннән алып , эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлеккә җибәрелә.

11. Муниципаль берәмлек, әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәр алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә кабат гариза бирергә хокуклы.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасында төзелгән килешү нигезендә бирелә.

13. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;

муниципаль берәмлекнең башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсе) билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәүне тикшереп тору тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

14. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме (Р) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P = \sum_{j=1}^{n} N_{(j)},$$

монда $N_{(j)}$ – Казан шәһәренең урам-юл челтәрендә юл билгеләрен урнаштыру, алыштыру, демонтажлау буенча эшләрне оештыру һәм үткәрү, башкарыла торган эшләр күләменә һәм юл билгеләре санына карап, чыгымнар күләме. Чыгымнар күләме муниципаль берәмлек тарафыннан тәкъдим ителгән проект-смета документациясе нигезендә билгеләнә.

15. Министрлык, эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә, башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән алып, килешү проектын имзалау өчен, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына җибәрә.

16. Килешү Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органыннан имзаланган килешү алынганнан соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә имзалана.

17. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар акчаларын күчерү, килешү төзелгән көннән алып, 10 көн эчендә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне исәпкә алу һәм аларны бүлү өчен, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган исәпкә алып, Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

18. Муниципаль берәмлек министрлыкка башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап һәм килешүдә каралган рәвешләр, сроклар һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалануның максатчан күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырырга тиеш.

19. Башка бюджетара трансфертларның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече- җирле үзидарә органы тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне үтәү, муниципаль берәмлекнең урам-юл челтәрендә юл билгеләрен урнаштыру (алмаштыру) белән бәйле.

Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән килешү һәм башка бюджетара трансфертларны куллануның фактта ирешелгән нәтиҗәлелек (нәтиҗә) күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

20. Муниципаль берәмлек Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау өчен җавап тота.

21. Әгәр башка бюджетара трансфертлар бирү елның 31 декабренә муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрне бозу очрагында һәм килешү нигезендә башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында хисап тапшыру датасына кадәр, күрсәтелгән бозулар бетерелмәгән булса, муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) елыннан соң килүче елның 1 мартына Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

$$V_{\text{кире кайтару}} = P \times k,$$

монда к - башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

Монда:

T - хисап чорында башка бюджетара трансфертларны куллану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән күрсәткече;

S - башка бюджетара трансфертларны куллану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең плandагы әһәмияте.

22. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган, әлеге Тәртип нигезендә алынган  башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә алынырга тиеш.

23. Министрлык һәм Татарстан Республикасы дәүләт финанс тикшерүе органнары әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

24. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган һәм (яисә) муниципаль берәмлек тарафыннан аларны бирү шартларын бозган очракта, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан

Республикасы бюджетына акчаларны кире кайтармаган очракта, аңа Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүриләү чаралары кулланыла.

25. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.